**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
ЧЕРЕМШАНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

23.06.2022 **Чирмешән авылы** №182

**2022 елда өч һәм аннан күбрәк савым сыеры булган шәхси ярдәмче хуҗалыкларга саву аппаратлары сатып алу чыгымнарының бер өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибен раслау турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Субсидияләр, шул исәптән юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә, шулай ук физик затларга - товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүчеләргә субсидияләр рәвешендә грантлар бирүне җайга салучы норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләр турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 2020 елның 18 сентябрендәге 1492 номерлы карары, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советының «2022 елга һәм 2023-2024 еллар план чорына Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы бюджеты турында» 2021 елның 18 декабрендәге 75 номерлы карары, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. 2022 елда өч һәм аннан күбрәк савым сыеры булган шәхси ярдәмче хуҗалыкларга савым аппаратлары сатып алу чыгымнарының бер өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибен расларга (1нче кушымта).
2. Әлеге карарны хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет
җитәкчесе И.Н. Шәйдуллин

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Башкарма комитеты карарына
1 нче кушымта
23.06.2022 ел №182

**2022 елда өч һәм аннан күбрәк савым сыеры булган шәхси ярдәмче хуҗалыкларга савым аппаратлары сатып алу чыгымнарының бер өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибе**

Әлеге тәртип 2022 елда өч һәм аннан күбрәк савым сыеры булган шәхси ярдәмче хуҗалыкларга  саву аппаратлары сатып алу чыгымнарының бер өлешен каплауга муниципаль район бюджетыннан субсидияләр бирү механизмын билгели (алга таба – шәхси ярдәмче хуҗалык, субсидияләр).

**Субсидияләр алу хокукына ия шәхси ярдәмче хуҗалыкларны сайлап алу категорияләре һәм критерийлары**

1.1. Шәхси ярдәмче хуҗалык (ЛПХ) - авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү һәм эшкәртү буенча эшкуарлык булмаган эшчәнлеге формасы. Шәхси ярдәмче хуҗалык гражданин яисә гражданин һәм аның белән яшәүче һәм (яки) аның белән бергә шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гаилә әгъзалары тарафыннан шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен бирелгән һәм (яки) шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен алынган җир кишәрлегендә шәхси ихтыяҗларын канәгатьләндерү максатларында алып барыла.

1.2. Сатып алынган саву аппаратлары өчен чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидияләр Чирмешән муниципаль районы составына керүче торак пунктларда теркәлгән һәм Чирмешән муниципаль районы территориясендә шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга милектә өч һәм аннан күбрәк савым сыеры булганда бирелә.

1.3. Субсидия гариза нигезендә бирелә.

**2. Субсидияләр бирү максатлары, шартлары һәм тәртибе**

2.1. Субсидияләр бирү максаты - савым сыерларының баш санын саклап калу һәм терлекчелек продукциясе җитештерүне тәэмин итү, шәхси ярдәмче хуҗалыкларда савым сыерларының баш санын арттыруны стимуллаштыру.

2.2. Субсидияләр 2022 елга һәм 2023-2024 еллар план чорына Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла.

Хуҗалыкларга субсидияләр бер елга бер шәхси ярдәмче хуҗалыкка 24 000 (егерме дүрт мең) сум исәбеннән бер тапкыр бирелә.

2.3. Шәхси ярдәмче хуҗалыкларга субсидияләр алу өчен авыл җирлеге башкарма комитетларына (алга таба – башкарма комитетларга) түбәндәге документлар тапшырыла:

- гариза, әлеге Тәртипкә 1 нче кушымта нигезендә;

- халыкның шәхси ярдәмче хуҗалыкларын исәпкә алу буенча хуҗалык кенәгәсеннән өземтә;

- әлеге Тәртипкә 2 нче кушымта нигезендә форма буенча субсидияләр бирү өчен исәп-хисап белешмәсе;

- гариза бирүченең паспорт күчермәсе;

- китерү шартнамәсе күчермәсе;

- счет-фактураның күчермәсе;

- товар накладнаясының күчермәсе;

- түләү турында квитанция күчермәсе;

- банк реквизитлары;

Шул исәптән, түбәндәгеләр турында белешмәләре булган мәгълүмат:

- шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданга карата Россия Федерациясе законнарында каралган банкротлык процедурасы кертелмәгән;

- Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән вазифасы юк.

2.4. Район башкарма комитеты:

а) субсидияләр бирү турындагы гаризаларны журналга кергән көнне теркиләр, ул номерланган, тегелгән һәм мөһер белән беркетелгән булырга тиеш, һәм тәкъдим ителгән документларны карыйлар. Документлар гаризаны теркәгәннән соң 5 көн эчендә карала;

б) әлеге Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән документлардагы белешмәләрнең дөреслеген тикшерәләр;

в) Тәртипнең 2.3 пунктында күрсәтелгән документлар нигезендә субсидияләр бирүгә җыелма белешмә-исәп-хисапларын төзиләр.

2.5. Өч эш көне дәвамында район Башкарма комитеты, авыл җирлеге башкарма комитеты һәм субсидия алучы Татарстан Республикасы Финанс-бюджет палатасы тарафыннан билгеләнгән типик форма буенча субсидия бирү турында килешүгә кул куялар.

2.6. Субсидияләр Татарстан Республикасы Финанс-бюджет палатасы тарафыннан билгеләнгән типлаштырылган форма нигезендә төзелгән субсидия бирү турындагы килешү нигезендә бирелә.

Субсидия алучыга бирелә торган субсидия күләме түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$V = S \times Z$,

кайда

V – Субсидия күләме

S – Эре мөгезле терлекләр саны

Z – чыгымнар күләме.

Субсидия бирү турында килешүдә карала:

- субсидия күләме, аның максатчан билгеләнеше;

- финанс белән тәэмин итү чыганагы булып субсидия торган чыгымнар юнәлешләре;

- субсидия күчерү тәртибе;

субсидия алучы тарафыннан чыгымнарны бюджеттан тыш (хосусый) финанслау буенча субсидия финанс тәэмин итү чыганагы булып торучы чыгымнар турында хисап бирү тәртибе, сроклары һәм формалары;

- агымдагы финанс елында хисап финанс елында файдаланылмый калган субсидияләрне кире кайтару тәртибе;

- субсидия алучының район Башкарма комитеты, Финанс-бюджет палатасы, Контроль-хисап палатасы тарафыннан субсидия бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүне тикшерү өчен ризалыгы

2.7. Район башкарма комитеты бюджет акчаларын баш бүлүче булып тора һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаментында ачылган шәхси счетыннан, субсидия алу өчен документлар тапшырганнан соң 10 көн эчендә гражданнарның банк счетларына күчерүне гамәлгә ашыра.

2.8. Баш бүлүче субсидия алучыларның субсидияләрен аларны җирле бюджеттан биргәндә билгеләнгән шартлар һәм максатлар нигезендә куллануына билгеләнгән тәртиптә финанс контролен гамәлгә ашыра.

2.9. Субсидияне нигезсез алу фактларын ачыклау, шулай ук субсидия алучы тарафыннан дөрес булмаган белешмәләр бирелгән очракта, Баш бүлүче субсидия алучының җирле бюджетка алынган субсидияне тулысынча кире кайтаруы турында карар кабул итә һәм 10 эш көне эчендә субсидия алучыга кабул ителгән карар һәм алынган субсидияне кире кайтару турында язмача хәбәр итә.

2.10. Субсидия алучы күрсәтелгән хәбәрнамәне алганнан соң 30 эш көне эчендә нигезсез алынган субсидияне җирле бюджетка күчерергә тиеш.

2.11. Субсидия алучы нигезсез алынган субсидияне җирле бюджетка әлеге Нигезләмәнең 2.10 пункты белән билгеләнгән срокта тулысынча күчермәгән очракта, күрсәтелгән акчалар баш бүлүче тарафыннан суд тәртибендә түләттерелә.

2.12. Район башкарма комитеты, Финанс-бюджет палатасы, районның Контроль - хисап палатасы субсидия алучыларга акча бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүне тикшерә.

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Башкарма комитеты раслаган
тәртипкә 1 нче кушымта
23.06.2022 № 182

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль
районы Башкарма
комитеты җитәкчесенә
______________________________
____________________________
(кемнән)
_______________________________

**ГАРИЗА**

Мин,______________________________________________________________,
(Ф.И.Ат.ис.)
Паспорт серия _____________ № _____________ бирелгән _________________________
________________________________________, адрес буенча яшәүче:
________________________________________________________________________,
телефон: ___________________________________, ИНН ______________________,
2022 елда өч һәм аннан күбрәк савым сыеры булган шәхси ярдәмче хуҗалыкка савым аппараты сатып алу өчен тотылган чыгымнарның бер өлешен каплауга тиешле субсидияне бирүегезне сорыйм (алга таба текст буенча – субсидия). ТР__________________________________________ адресы буенча урнашкан шәхси хуҗалыкта савым сыерларының саны 2022 елның 1 гыйнварына булган мәгълүматлар буенча _________________________ (__________________________________) баш тәшкил итә дип хәбәр итәм.

Катнашу шартлары һәм субсидияләр бирү тәртибе белән таныштырылган һәм ризамын.

Тәкъдим ителгән документлардагы яисә аларның күчермәләрендәге барлык мәгълүмат чын булып тора һәм субсидия бирүгә документларны карауда катнашучы затларның аннан файдалана алуына каршы түгел.

_____________ /______________ /                    «____» __________20_ел
(Имза)                    (Ф.И.Ат.ис.)

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Башкарма комитеты раслаган
тәртипкә 2 нче кушымта
23.06.2022 ел № 182

«Раслыйм»
Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе

_______________ ________________________
(имза) (Ф.И.Ат.ис.)
«_____» ________________ 20_ ел

«Килешенде»
Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы ______________________ авыл җирлеге башлыгы

_______________
________________________
(имза) (Ф.И.Ат.ис.)
«_____» ________________ 20_ ел

## 2022 елда сатып алынган саву аппараты өчен чыгымнар өлешен каплауга өч һәм аннан күбрәк савым сыеры булган гражданнарга субсидияләр бирү турында белешмә-исәп

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының ______________________ авыл җирлеге буенча

ОКАТО ____________________

| № п\п | Шәхси ярдәмче хуҗалык хуҗасының ФИА | Яшәү урыны | ИНН | Паспорт белешмәләре | Савым сыерларының баш саны, баш. 01.01.2022 | Бер шәхси ярдәмче хуҗалыкка субсидия ставкасы, сум. | Барлыгы субсидияләр, сум. |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |

Белешмәләрнең дөреслеген раслыйбыз:
Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы
______________________ авыл җирлеге башлыгы

_______________________ /__________________________________
(имза) (Ф.И.Ат.ис.)

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы
__________________ авыл җирлегенең баш хисапчысы

_____________ /___________________
(имза) (Ф.И.Ат.ис.)